# Туганнарым, сәлам сезгә

Запись Масгуды Шамсутдиновой




Карасам йөзегез якты, җыйдырган табыныгыз татлы,
Фирештәләр әҗере язсын кыямәт көненә чаклы.
Каю өйдә изге мәҗлес, фирештәләр анда иңәр,
Догага кул күтәргәндә алар безгә амин дияр.
И, Ходаем, үзең бирдең газиз җанны, шәриф тәнне,
Мөхәммәт өммәтеннән кылган Ходаем барча бәндәне.
Иляһи, үзең беләсең кальбебезнең моңнарыни,
Ахирәттә насыйб әйлә барыбызга дидарыңный.
Минем сезгә юктыр бүләк, бүләгемдер - изге теләк,
Кыямәт көне булганда булса иде йөзебез ак.
Гамәлләр булмасын сулдан, үзебез булмаек көфер,
Мөхәммәд өммәте кылдың, Әлхәмделилләһи шөкер.
Аңа өммәт кылу белән безне хөрмәтләде Аллаһы,
Мәхшәр җиренә барганда шәфәгать кыл, Рәсүлюллаһы.
Кыямәт көне булганда, мизан дәрзү кылганда,
Гасый өммәтләрең өчен шәфәгать кыл, Рәсүлюлла.
И, Ходаем, сорый Синнән дүрт нәрсәне бирүеңне,
Бери Иман, бери аман, бери дәүләт, бери Җәннәт.

©